**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 22 октябрь № 769

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 315 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 315 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 29 декабрь, 663 нче; 2006 ел, 2 май, 216 нчы; 2008 ел, 27 июнь, 449 нчы; 2009 ел, 13 июль, 491 нче; 2010 ел, 11 июнь, 465 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1035 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 29 август, 724 нче; 2011 ел, 29 август, 726 нчы; 2012 ел, 8 сентябрь, 761 нче; 2013 ел, 19 март, 190 нчы; 2014 ел, 1 февраль, 54 нче; 2014 ел,11 март, 150 нче; 2014 ел, 16 май, 325 нче; 2014 ел, 26 декабрь, 1042 нче; 2015 ел, 30 июнь, 472 нче; 2016 ел, 13 май, 301 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган һәм Татарстан Республикасы карамагындагы оешмаларның педагогика хезмәткәрләре, мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыра һәм физик культура һәм спорт өлкәсендә белем бирү программаларын тормышка ашыра торган муниципаль һәм шәхси оешмаларның педагогика хезмәткәрләренең квалификация категорияләрен билгеләү максатларында аттестация үткәрү өчен аттестация комиссиясен формалаштыра.»;

түбәндәге эчтәлекле 4.1.1 пункт өстәргә:

«4.1.1. Министрлыкның структур бүлекчәләре һәм хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү министр боерыгы белән расланган нәтиҗәлелек күрсәткечләре исемлеге нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

4.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«министр урынбасарлары, структур бүлекчәләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелегенең төп күрсәткечләре исемлеген боерыгы белән раслый;

Министрлыкка беркетелгән процессларны (ярдәмче процессларны) үтәү стандартларын боерыгы белән раслый һәм аларны үтәүне тәэмин итә;

эшчәнлек нәтиҗәлелегенең төп күрсәткечләренә ирешү нәтиҗәләре нигезендә Министрлыкның структур бүлекчәләре һәм хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү турында нигезләмәне, шулай ук эшчәнлек нәтиҗәлелегенең ирешелгән төп күрсәткечләренә бәйле стимуллаштыра торган түләүләр зурлыгын исәпләү тәртибен билгеләү турында нигезләмәне боерыгы белән раслый;

Министрлык өчен билгеләнгән нәтиҗәлелекнең төп күрсәткечләре һәм хезмәт законнары нигезендә үз карамагындагы учреждениеләр җитәкчеләре белән контрактлар (хезмәт шартнамәләренә өстәмә килешүләр) төзи.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\769.docx